**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4068**
**18.05.2023**

Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 2 июлендәге 975 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 25 сентябрендәге 4863 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 3 августындагы 3706 номерлы карары редакциясендә) белән расланган «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

- физик затның – бюджетка түләүләрне түләүченең үлемен таныклый яки аны үлгән дип белдерү фактын раслый торган документ;

- конкурс производствосы тәмамлану яки шәхси эшмәкәр булып торган гражданның – бюджетка түләүләр түләүченең мөлкәтен сату тәмамлану турында суд акты, шулай ук аны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителү сәбәпле, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан физик зат – бюджетка түләүләр түләүче тарафыннан шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктату турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

- конкурс производствосы тәмамлану яки гражданның – бюджетка түләүләр түләүченең мөлкәтен сату тәмамлану турында суд акты;

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан оешманы – бюджетка түләүләр түләүчене бетерү сәбәпле, эшчәнлеген туктату турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан юридик затны – бюджетка түләүләр түләүчене теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

- хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки штраф рәвешендә ярлыкау турында акт яки аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;

- суд приставы-башкаручының «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча, түләтүчегә башкару документын кире кайтару сәбәпле, башкару производствосының тәмамлануы турында карары;

- банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, банкротлык турындагы эш буенча производствоны туктату яки бурычлы затны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында суд акты;

- административ җәза билгеләү турында карарны үтәүне туктату турында карар.»;

2) 19 пунктның 2 пунктчасында «(физик затның салым түләүченең идентификация номеры)» сүзләрен «(физик затның салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов